АРБОР ТӨП ГОМУМИ БЕЛЕМ МӘКТӘБЕ

# ЮЛГА ЧЫКТЫК БЕЗ БЕРГӘ...

СЫЙНЫФ БЕЛӘН ЭШЛӘҮ ӨЧЕН

ЮЛ ЙӨРҮ КАГЫЙДӘЛӘРЕН ӨЙРӘТҮ БУЕНЧА

ШӘХСИ ИҖАДИ ТӘРБИЯ ПРОГРАММАСЫ

Төзеде: Мифтахова Р.Б.

**Норматив документлар:**

1. Россия Федерациясе Конституциясе.
2. РФ «Мәгариф турындагы» Законы.
3. «Бала хокукларытурындагы» Конвенция.
4. Мәктәпнең Уставы.
5. Юл йөрү кагыйдәләре.

## Аңлатма язуы.

Хәзерге транспорт көннән көн арткан заманда яшәүче балалар бик еш кына төрле юл фаҗигаләренең шаһитләре генә түгел, кызганычка каршы, корбаннары да булалар. Фаҗигаләрдә өлкәннәр, транспорт йөртүчеләр генә түгел, балалар да гаепле булган очраклар арта. Шуңа да балалар катнашындагы юл-транспорт фаҗигаләре проблемасы актуаль булып кала. Өлкән кеше юлда үз-үзен контрольдә тота алса да, балалар өчен бу шактый кыен. Юл аша тиешле җирдә чыкмау, караңгы вакытта киемнәрдә махсус яктырткычлар булмау, светофорга игътибар итмәү кебек беренче карашка бик гади генә булган “вак” кагыйдә бозулар коточкыч зур фаҗигаләргә китерә. Юллардагы тән җәрәхәте алуның артуы дөньякүләм проблемага әверелде. Ә тән җәрәхәте төзәлгәннән соң да психикасы какшап калган, гомерлек җан җәрәхәте алган балалар күпме?!

Балалар катнашындагы юл-транспорт һәлакәтен профилактикалау, укучыларны төрле чаралар ярдәмендә урамда һәм юлларда юл йөрү кагыйдәләрен төгәл үтәргә өйрәтү – мөһим мәсьәләләрнең берсе. Балалар кече яшьтән үк юл йөрү кагыйдәләре белән таныштыру, өйрәтү, төрле ситуацияләрдә үз-үзләрен ничек тотарга кирәклеген аңлату зарур. Юл йөрү кагыйдәләре белән кечкенәдән таныш бала юлда үзен җаваплырак, акыллырак, игътибарлырак тота. Үзенең һәм башкаларның тормышы, иминлеге һәм сәламәтлеге турында кайгырта белү – һәр кешенең бурычы, намус эше.

**Программаның максаты:**

- балаларкатнашындагыюл-транспорт һәлакәтенпрофилактикалау,
- укучыларнытөрлечараларярдәмендәурамдаһәмюллардаюлйөрүкагыйдәләрентөгәлүтәргә өйрәтү,
- балаларныңигътибарлылыгын,мөстәкыйльэзләнүен, иҗадисәләтләренүстерү.

**Бурычлар:**

- укучыбалаларныюллардаүз-үзеңнетотукагыйдәләренәтөшендерү;
- укучыларны юлйөрүкагыйдәләренең тарихы белән таныштыру;
- юлдаүз-үзеңнетотабелүкультурасынформалаштыру;
- таныпбелү, иҗадикүзаллау, иҗадификерләүсәләтләрен камилләштерү;
- аралашу, коммуникативосталыкларынүстерү;

**Укучылар белергә тиеш:**

1. юл йөрү кагыйдәләренең тарихын;
2. юл билгеләрен;
3. светофор сигналларын;
4. транспорт төрләрен;
5. юл фаҗигаләренең сәбәбен;
6. велосипедта йөрү кагыйдәләрен;
7. юл йөрү кагыйдәләрен.

**Укучылар тиеш:**

1. юл хәрәкәтендә ориентлаша белергә;
2. юлда үзен бәяли белергә;
3. үз иптәшләренә юл йөрү кагыйдәләрен аңлата белергә.

**Көтелгән нәтиҗә:**

- Укучылар катнашындагы юл-транспорт фаҗигаләренең кимүе,
- Юл йөрү кагыйдәләре буенча белемнәре арту.

**Программа түбәндәге принципларга нигезләнеп төзелде:**

- юл йөрү кагыйдәләрен системалы өйрәнү,
- өйрәнелгәнне аңлы рәвештә кабул итү,
- яшь үзенчәлекләреннән чыгып, яңа материалның күләмен арттыру.

**Үткәрү формалары:**

- тематик чаралар
- әңгәмә
- дискуссия
- конкурс
- уен
- диспут
- төркемнәрдә эш
- өстәл уеннары
- маршрут төзү
- эзләнү эшләре
- проектлар

**Календарь-тематикпланлаштыру**

**5 нчы сыйныф:**

| № | **Тема** | **дата** |
|---|---|---|
| 1 | Кереш инструктаж. Без юлдан йөрибез. Юл билгеләре. | сентябрь |
| 2 | Светофор. Юл аша чыгу урыннары. | сентябрь |
| 3 | Юл билгеләре. Викторина. Көзге каникулга инструктаж. | октябрь |
| 4 | Зебра. Велосипедта йөрү. | ноябрь |
| 5 | Җәяүлеләр өчен иң куркыныч очраклар. Кышкы каникулга инструктаж. | декабрь |
| 6 | “Яшерен” куркынычлар. Юл “тозаклары”. | январь |
| 7 | Гомуми маршрут транспортында йөрү кагыйдәләре. | февраль |
| 8 | Һава торышы һәм юл йөрү кагыйдәләренең “дуслыгы”. Язгы каникулга инструктаж. | март |
| 9 | ЮХИДИ эшчәнлеге. ЮХИДИ хезмәткәрләре белән очрашу. | апрель |
| 10 | Гомуми кабатлау. Уен-дәрес. Җәйге каникулга инструктаж. | май |

**6 нчы сыйныф:**

| № | Тема | дата |
|---|---|---|
| 1 | Кереш инструктаж. Юл йөрү кагыйдәләрен кабатлау. | сентябрь |
| 2 | Юллар чатында: чатлар төре, кагыйдәләр (перекресток) | сентябрь |
| 3 | Юл хәрәкәтендә катнашучылар. Көзге каникулга инструктаж. | октябрь |
| 4 | Җәяүленең бурычлары. | ноябрь |
| 5 | Җәяүленең кышкы белешмәлеге. Кышкы каникулга инструктаж. | декабрь |
| 6 | Транспорт чараларының хәрәкәте, тизлеге, туктау һәм тормоз юллары. | январь |
| 7 | Юл һәлакәтенә китерергә мөмкин шартлар. | февраль |
| 8 | Юл һәлакәтен булдырмау өчен нәрсәләр белергә, яки эшләргә мөмкин. Язгы каникулга инструктаж. | март |
| 9 | Юл билгеләре: 8 группа билге. | апрель |
| 10 | Иминлек – иң мөһиме. Җәйге каникулга инструктаж. | май |

**7 нче сыйныф:**

| № | Тема | дата |
|---|---|---|
| 1 | Кереш инструктаж. Юл йөрү кагыйдәләрен кабатлау. | сентябрь |
| 2 | Велосипед, мопед, скутерда йөрү кагыйдәләре: техник таләпләр, идарә итү хокукы һб | сентябрь |
| 3 | Юл хәрәкәтендә катнашучыларның бурычлары, аларга таләпләр. Көзге каникулга инструктаж. | октябрь |
| 4 | Җәяүленең бурычларын кабатлау. | ноябрь |
| 5 | Кышкы юллар кыенлыгы. Кышкы каникулга инструктаж. | декабрь |
| 6 | Транспорт чаралары һәм пассажирларның бурычлары. | январь |
| 7 | Юл һәлакәтенә китерергә мөмкин шартлар, ничек сакланырга. | февраль |
| 8 | Беренче ярдәм күрсәтү. Язгы каникулга инструктаж. | март |
| 9 | Юл билгеләре, светофор, зебра һб мөһим төшенчәләр. | апрель |
| 10 | Иминлек турында һәрчак истә тотыйк! Җәйге каникулга инструктаж. | май |